ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 декабря 2025г. № 10851

Башкарма комитетның 2025 елның 30 гыйнварындагы 561 номерлы Карары белән расланган Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәткә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 6 сентябрендәге 669 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 31 декабрендәге 1097 номерлы Карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 26 сентябрендәге 757 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 сентябрендәге 763 номерлы Карары , Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2025 елның 30 гыйнварындагы 561 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2025 елның 9 июнендәге 4114 номерлы Карары редакциясендә) расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлар) түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 25 650 |
| 2 | 1,0113 | 25 940 |
| 3 | 1,0234 | 26 250 |
| 4 | 1,0347 | 26 540 |
| 5 | 1,0476 | 26 871 |
| 6 | 1,0596 | 27 180 |
| 7 | 1,0729 | 27 520 |
| 8 | 1,0858 | 27 851 |
| 9 | 1,0982 | 28 170 |
| 10 | 1,1119 | 28 520 |
| 11 | 1,1251 | 28 860 |
| 12 | 1,1392 | 29 220 |
| 13 | 1,1536 | 29 590 |
| 14 | 1,1676 | 29 950 |
| 15 | 1,1825 | 30 331 |
| 16 | 1,1973 | 30 711 |
| 17 | 1,2125 | 31 100 |
| 18 | 1,2281 | 31 501 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклад) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.»;

2) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Яр Чаллы шәһәренең «Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы» муниципаль бюджет учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Шәхси состав буенча документлар архивы» муниципаль бюджет учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Тантаналар сарае» муниципаль автономияле учреждениесе, Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары 16 928 сумга тапкырлап исәпләнә. Күрсәтелгән җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең вазыйфаи окладларының арттыру коэффициентлары һәм күләме түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Калдыксыз бүлү коэффициенты | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 | 38 088 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 2,0 | 33 856 |
| Бүлек башлыгы | 1,65 | 27 932 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,55 | 26 239 |
| Баш белгеч | 1,4 | 23 700 |
| Әйдәүче белгеч | 1,17 | 19 806 |
| I категорияле белгеч | 1,12 | 18 960 |
| II категорияле белгеч | 1,1 | 18 621 |
| Белгеч | 1,08 | 18 283»; |

3) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләме түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|
| Җитәкче | 42 152 |
| Җитәкченең беренче урынбасары;<br>җитәкче урынбасары | 39 728 |
| Бүлек башлыгы | 31 084 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 27 978 |
| Баш белгеч | 25 475 |
| Әйдәүче белгеч | 23 201»; |

4) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициенты һәм вазыйфаи окладның күләме түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Коэффициент | Вазыйфаи оклад күләме сумнарда |
|---|---|---|
| Склад мөдире, таксировщик, участок мастеры (өлкәнен дә кертеп) | 1,0 | 16 928»; |

5) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Аерым оешмалар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләрнең вазыйфаи оклады Бердәм тариф челтәре нигезендә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 25 650 |
| 2 | 1,0113 | 25 940 |
| 3 | 1,0234 | 26 250 |
| 4 | 1,0347 | 26 540 |
| 5 | 1,0476 | 26 871 |
| 6 | 1,0596 | 27 180 |
| 7 | 1,0729 | 27 520 |
| 8 | 1,0858 | 27 851 |
| 9 | 1,0982 | 28 170 |
| 10 | 1,1119 | 28 520 |
| 11 | 1,1251 | 28 860 |
| 12 | 1,1392 | 29 220 |
| 13 | 1,1536 | 29 590 |
| 14 | 1,1676 | 29 950 |
| 15 | 1,1825 | 30 331 |
| 16 | 1,1973 | 30 711 |
| 17 | 1,2125 | 31 100 |
| 18 | 1,2281 | 31 501»; |

6) 28 пунктның 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

Учреждение җитәкчесенең һәм хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары

| Вазыйфасы, исеме | Вазыйфаи окладның күләме (сум) |
|---|---|
| Җитәкче | 40 169 |
| Баш бухгалтер | 28 119 |
| Каравыл башлыгы | 33 961 |
| Янгын сүндерү бүлеге командиры | 32 851 |
| Янгын сүндерү машинасын йөртүче | 29 618 |
| Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенең структур бүлекчә җитәкчесе | 33 345 |
| Оператив дежур | 25 650». |

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов